ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АГРЫЗСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ул. Гагарина, д.13, г. Агрыз, 422230

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ӘГЕРҖЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫң БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Гагарин ур.,13, Әгерҗе шәһәре, 422230

Тел.: (85551) 2-22-46; Факс: 2-22-46; E-mail: isp.agryz@tatar.ru; www. agryz.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«10» апреля 2026 ел № 87

«2026-2028 елларга Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районында физик культураны һәм спортны үстерү» муниципаль программасын раслау турында» Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитетының 19.01.2026 елның 05 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 14.02.2026 елның 271-р номерлы күрсәтмәсе нигезендә, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. «2026-2028 елларга Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районында физик культураны һәм спортны үстерү» муниципаль программасын (алга таба - муниципаль программа) раслау турында» Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитетының 19.01.2026 елның 05 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Муниципаль программа паспорты. Программаны финанслау чыганакларын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

<table>
<tr><td rowspan="3">Программаны финанслау күләмнәре һәм чыганаклары:</td><td colspan="3">Программаны Әгерҗе муниципаль районы бюджетыннан финанслауның гомуми күләме:</td></tr>
<tr><td>ел</td><td>Җирле бюджет</td><td>Республика бюджеты</td></tr>
<tr><td>2026 ел</td><td>199,8 мең сум</td><td>209,71 мең сум (спорт инвентаре);<br>298,1 мең сум (хоккей буенча программаларны гамәлгә ашыруга)<br>20,0 мең сум (яшь белгечләргә акча түләүгә),<br>100,0 мең сум югары квалификацияле спортчылар әзерләгән өчен тренер-укытучыларга, шулай ук спортчыларга спорт резервын әзерләүче муниципаль физкультура спорт оешмаларында эшләүче ярышларда алынган нәтиҗәләр өчен спорт чаралары өчен - инструкторларга һәм спортчыларга бүләкләүгә</td></tr>
</table>

| | | | |
|---|---|---|---|
| | 2027 ел | 199,8 меӊ сум | - |
| | 2028 ел | 199,8 меӊ сум | - |
| | Барлыгы | 599,4 меӊ сум | 627,81 |

1.2. 6 нчы таблица. 2026-2028 елларга Әгерҗе муниципаль районында физик культураны һәм спортны үстерү чаралары:

1.2.1. 5 нче бүлек. Матди-техник базаны үстерүгә 5.4 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| № | Чараларның эчтәлеге | Үтәү срогы | Үткәрү өчен җаваплы | Финанслау күләме (меӊ сум) | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | 2026 | 2027 | 2028 |
| 5.4 | Спорт мәктәпләрен җиһазландыру өчен спорт җиһазлары, экипировка һәм инвентарь сатып алуга Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты күрсәтмәсе нигезендә бюджетара трансфертлар. (республика бюджеты) | 2026-2028еллар | ТР ӘМР "Спорт мәктәбе" ӨББ МБУ | 209,71 | | |

1.2.2. 5 нче бүлек. Матди-техник базаны үстерүгә түбәндәге эчтәлекле 5.5 пункт өстәргә:

| № | Чараларның эчтәлеге | Үтәү срогы | Үткәрү өчен җаваплы | Финанслау күләме (меӊ сум) | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | 2026 | 2027 | 2028 |
| 5.5 | Югары квалификацияле спорт-чылар әзерләгән өчен тренер-укытучыларга, шулай ук спорт-чыларга спорт резервын әзер-ләүче муниципаль физ-мәдәни спорт оешмаларында эшләүче ярышларда алынган нәтиҗәләр өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан бюджетара транс-фертлар | 2026-2028еллар | ТР ӘМР "Спорт мәктәбе" ӨББ МБУ | 100,0 | | |

1.2.3. 6 нче бүлек. 6.3, 6.6 п. спорт төрләрен үстерүдә өстенлекләрне түбәндәгечә бәян итәргә:

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 6.3 | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары нигезендә спорт мәктәпләренә спорт әзерләү программаларын гамәлгә ашыруга һәм хоккей буенча Татарстан Республикасы чемпионатында (республика бюджеты) спорт командаларының катнашуына бюджетара трансфертлар | 2026-2028еллар | ТР ӘМР "Спорт мәктәбе" ӨББ МБУ | 298,1 | | |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 6.6 | Спорт резервын әзерләүче муниципаль физкультура спорт оешмаларында эшләүче яшь белгечләргә акчалата түләүләрне гамәлгә ашыруга Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты күрсәтмәсе белән расланган бюджетара трансфертлар | 2026-2028еллар | ТР ӘМР "Спорт мәктәбе" ӨББ МБУ | 20,0 | | |

3. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Финанс-бюджет палатасына «Физик культура һәм спорт»тармакларында каралган бюджет акчалары кысаларында муниципаль программа чараларын гамәлгә ашыруга бюджет акчалары бүлеп бирүне тәэмин итүне тәкъдим итәргә.

4. Әлеге карарны "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында бастырып чыгарырга (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга (http://agryz.tatarstan.ru).

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

**Җитәкче урынбасары** **Р.Н. Бадахшин**